МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

20.09.2021 г.Казань № 670

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 4 октяберендә 7952 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 20.06.2019 №484, 16.08.2019 №624, 14.11.2019 №1023, 18.06.2020 №436, 27.07.2020 №536, 24.09.2020 №669, 18.12.2020 №876, 02.06.2021 №388 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2021 елның
20 сентябрендәге 670 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерыкта:

боерык атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

боерыкның 1 пунктында «социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта:

Административ регламент атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 бүлектә:

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Учреждениенең урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, Министрлыкның рәсми сайты адресы, Министрлыкның электрон почтасы, Министрлыкның территориаль органнары, дәүләт хезмәте күрсәтергә вәкаләтле булган оешмаларының адреслары турындагы мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты, «Интернет» челтәре), «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы) урнаштырылган. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктында:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

Республика порталында;

Бердәм порталда.

Бердәм порталда, Республика порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) күпфункцияле үзәккә һәм (яки) күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарына мөрәҗәгать иткәндә.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Әлеге Регламент максатларында түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү) – гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге;

социаль хезмәт күрсәтү – тормыш шартларын яхшырту һәм тормышындагы төп ихтыяҗларын мөстәкыйль тәэмин итә алу мөмкинлекләрен арттыру максатларында, гражданинга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә даими, билгеле бер вакыт ешлыгы белән, бер тапкыр, шул исәптән ашыгыч, ярдәм күрсәтү;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмалар һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада да, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләт бирелгән оешма;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

ИАБС – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 3 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать. Гаризаның формасы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза формасын раслау турында» 2014 елның 28 мартындагы 159н номерлы боерыгы (алга таба – РФ Хезмәт министрлыгының 159н номерлы боерыгы) белән расланган.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү.

2.2. Башкарма хакимият органының исеме

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) гражданинның яшәү урыны (тору урыны) буенча Социаль яклау идарәләре (бүлекләре) аша Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Министрлык тарафыннан гражданнарны балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм Татарстан Республикасының бер яисә берничә муниципаль берәмлеге территориясендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү вәкаләте бирелгән балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләре (әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы исемлек).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын (алга таба – индивидуаль программа) төзү;

яисә гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану очрагында аңа (аның законлы вәкиленә) социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү датасы һәм урыны турында хәбәр ителә.

2.3.2. Кабул ителгән карар турында мәгълүмат рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә аны алу буенча сайлаган ысул белән җибәрелә:

почта аша язма рәвештә;

электрон документ формасында электрон почта адресы яки мөрәҗәгать итүченең Республика порталындагы шәхси кабинетына.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар гариза тапшырылган көннән башлап биш эш көне эчендә кабул ителә.

Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кичекмәстән кабул ителә.

2.4.2. Гариза тапшырылганнан соң ун эш көненнән артмаган вакыт эчендә гражданинга социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы төзелә һәм аның төзелүе һәм аны алу өчен территориаль органга чакыру турында хәбәр җибәрелә.

Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы төзелми.

2.4.3. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза бирә:

РФ Хезмәт министрлыгының №159н боерыгы белән расланган форма буенча кәгазьдә;

Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, әлеге пункт таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2.5.2. Комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка 2 нче кушымтадагы исемлеккә туры китереп документлар да тапшыра.

Картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларында (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 3 кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернет йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 4 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балаларның интернет йортларында, физик җитешсезлекләре булган балаларның интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 5 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплексы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә стационар формада социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ булган балигъльк яшенә җитмәгән затлар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен социаль

тернәкләндерү үзәкләре) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка 7 нче кушымтадагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән бергә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 8 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Яшәү белән бергә алып барыла торган уку (күнекмә алу) курсы кысаларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка $8^1$ кушымтадагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм итү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 9 нчы кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән бергә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 10 нчы кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Сукырларны һәм начар күрә торган затларны социаль тернәкләндерү үзәгендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 11 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

2020-2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру бөенча сынау проектында катнаша торган социаль хезмәт күрсәтүче затлар тарафыннан көндезге бүлекчәләрдә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән бергә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның $11^1$ кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм итү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 12 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә мөрәҗәгать итүче шәхесне раслый торган документ күрсәтә. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза законлы вәкил тарафыннан тапшырылган очракта яисә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләрнең вәкилләре мөрәҗәгать

иткән очракта, вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен таныклый торган документлар күрсәтелә.

Документларның күчермәләре, Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта, оригиналларын күрсәтеп, Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты тарафыннан раслана.

2.5.3. Гариза һәм теркәп тапшырыла торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән;

почта аша почта юлламасы белән;

Республика порталы аша электрон формада;

күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы (алга таба – Бердәм портал) аша электрон формада.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар. Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Гаризаны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша яисә Республика порталы, Бердәм портал аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага), күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин.

Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

## 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы,

җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәге документлар алына:

әлеге Регламентның 13 нче кушымтасындагы исемлек буенча халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында;

әлеге Регламентның 14 нче кушымтасындагы исемлек буенча картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларында (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентка 15 нче кушымтадагы исемлек буенча психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентка 16 нчы кушымтадагы исемлек буенча психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балаларның интернет йортларында, физик җитешсезлекләре булган балаларның интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентка 17 нче кушымтадагы исемлек буенча инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентның 18 нче кушымтасындагы исемлек буенча социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ булган балигълык яшенә җитмәгән затлар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен социаль тернәкләндерү үзәкләре) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентка 19 нчы кушымтадагы исемлек буенча билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

19[1] кушымтадагы исемлек буенча яшәү белән бергә алып барыла торган уку (күнекмә алу) курсы кысаларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентның 20 нче кушымтасындагы исемлек буенча гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм итү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында;

әлеге Регламентка 21 нче кушымтадагы исемлек буенча халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында;

әлеге Регламентка 22 нче кушымтадагы исемлек буенча сукырлар һәм

начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәгендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында;

әлеге Регламентның 22[1] кушымтасындагы исемлек буенча 2020-2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру бөенча сынау проектында катнаша торган социаль хезмәт күрсәтүче затлар тарафыннан көндезге бүлекчәләрдә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында;

әлеге Регламентның 23 нче кушымтасындагы исемлек буенча гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм итү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында;

Мөрәҗәгать итүче Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүченең паспорты чын булуын раслау турындагы мәгълүмат та алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

2.6.2. Әлеге пунктта күрсәтелгән документларны, гади электрон имза белән имзаланган электрон формада, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, аша Министрлыкның территориаль органына мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән;

почта аша почта юлламасы белән.

2.6.3. Югарыда күрсәтелгән документлар әлеге Регламентның 13-23 кушымталарында күрсәтелгән оешмалардан һәм учреждениеләрдән, тиешле федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларында (норматив актларында) билгеләнгән ысуллар белән алынырга мөмкин.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларны кабул итүдән баш тартуга нигез була алмый.

Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

Әлеге органнарның соралган һәм карамакта булган документны яки мәгълүматны тапшырмаган (үз вакытында тапшырмаган) вазыйфаи заты һәм (яки) хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә административ, дисциплинар яки башка төрле җаваплылыкка тартылырга тиешле була.

2.6.5. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы

яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

2) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

3) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны.

4) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту (документларны асылы буенча карамыйча кире кайтару) нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:

1) әлеге Регламентның 2.5.2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырылырга тиешле документларның тапшырылмавы;

2) документларның тиешле булмаган органга тапшырылуы;

3) төгәл булмаган һәм (яки) кара-каршы килә торган белешмәләр, җитди, эчтәлеген бер мәгънәдә аңлау мөмкинлеген бирми торган җитешсезлекләре булган документларның, гамәлдән чыккан документларның тапшырылуы, тапшырылган документларда чистартылган, өстәп язылган, сызып ташланган сүзләр һәм билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган төзәтүләр булуы;

4) күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү;

5) мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

6) гаризаның электрон формасындагы мәҗбүри кырларны төгәл тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булуы;

7) 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләре

нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон формадагы гариза (мөрәҗәгать) һәм башка документлар;

8) электрон документларның аларның форматларына карата таләпләргә туры килмәве һәм (яки) укылмавы;

9) законлы вәкилләр турында мөрәҗәгать итүче тапшырган белешмәләрнең расланмавы, гризаның (рәсми мөрәҗәгатьнең) мөрәҗәгать итүче исеменнән моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең исемлеге тулы булып тора.

2.7.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру, гамәлдә булу срогы чыккан документлар һәм белешмәләр бирү;

2) гражданинның тормыш эшчәнлеге шартларын начарайта яисә начарайта ала торган шартлар булмавы;

3) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган, социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен медицина каршылыкларының булуы ачыклану.

4) законлы вәкилләр турында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган белешмәләрнең расланмавы, гризаның (рәсми мөрәҗәгатьнең) мөрәҗәгать итүче исеменнән моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы.

2.8.2. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гриза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Заруриһәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Заруриһәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

### 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Мөрәҗәгать итүчене кабул итү (хезмәт күрсәтү) көтү вакытының максималь вакыты 15 минуттан артмый.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затларның аерым категорияләре өчен кабул итүне көтү чираты билгеләнмәгән.

### 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын һәм документларны, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү чоры һәм тәртибе

2.13.1. Шәхсән мөрәҗәгат иткән очракта, гариза һәм документлар алынган көнне.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада алынган гаризалар һәм документлар ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

### 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында

каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз үтеп керә алу максатларында, түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән хезмәттән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-ноктал хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, хезмәтләр күрсәтелә торган объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.3. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, хезмәт күрсәтү;

в) хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, аларга хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) хезмәт күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктаны хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.4. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен (шул исәптән тулы күләмдә) күрсәтү мөмкинлегенең булуы яки булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачау итүче каршылыкларны җиңәргә ярдәм күрсәтелүе;

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Министрлыкның территориаль органы (учреждение, вәкаләтле оешма) белгечлщре тарафыннан Регламент бозылуга карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның территориаль органы (учреждение, вәкаләтле оешма) белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

гариза һәм документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль законның һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар формасында җибәрелгән очракта, – бер тапкырдан артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.3. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы белгечләр белән бер тапкыр үзара хезмәттәшлек итүенең вакыты буенча озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.15.4. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

гаризаны һәм документларны Республика порталы, Бердәм портал аша биргән мөрәҗәгать итүче тарафыннан – Республика порталында, Бердәм порталда;

гаризаны һәм документларны кәгазь чыганакта тапшырган мөрәҗәгать итүче тарафыннан – гариза буенча почта адресына кәгазь чыганакта.

күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынында.

2.15.5. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза Министрлыкның территориаль органына теркәлгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлыкның территориаль органы белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык һәм күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.15.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм документларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон формада алырга;

е) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлыкның территориаль органы, Учреждение, Вәкаләтле оешма белгече, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне Министрлыкның территориаль органына кабул итү өчен язу (алга таба – кабул итүгә язылу) Республика порталы, Бердәм портал аша гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүчегә Министрлыкның территориаль органында билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә буш булган теләсә нинди кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Республика порталы, Бердәм портал аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номеры;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның

гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.16.4. Гариза Республика порталы, Бердәм портал аша җибәрелергә мөмкин.

Гариза Республика порталы, Бердәм портал аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризаны һәм документлар комплектын кабул итү һәм карау;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны һәм тапшырылган документларны (документларның күчермәләрен) карау, социаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны (мөрәҗәгатьне) социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булу турында карар кабул итү өчен кирәкле документларны (документларның күчермәләре) белән бергә кабул итү һәм теркәү яисә гариза белән документларны кабул итүдән баш тарту.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыра.

Социаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗ булуын билгели торган, гаризада (мөрәҗәгатьтә) күрсәтелгән шартлар булуын раслый торган документлар (документларның күчермәләре) гариза белән берлектә гражданин (аның законлы вәкиле) тарафыннан, ә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре мөрәҗәгать иткән очракта – башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмаларның вәкилләре тарафыннан тапшырыла, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү очраклары искәрмә булып тора.

Гариза һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның күчермәләре почта юлламасы итеп җибәрелергә мөмкин.

3.2.2. Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында, Бердәм порталда авторизацияләнә;

Республика порталында, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5.4 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның һәм документларның җибәрелүе турында белдерү ала.

Почта аша тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре), электрон формада Республика порталы, Бердәм портал, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) гомуми тәртиптә карала.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

3.2.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә законлы вәкиле аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар теркәп, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына кәгазьдә гариза һәм документлар тапшыра ала.

Күпфункцияле үзәкнең гаризаларны һәм документларны кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

3.2.4. Күпфункцияле үзәк белгече гариза һәм документларны Министрлыкның территориаль органына җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлыкның территориаль органы белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның территориаль органына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

Министрлыкның территориаль органы белгече (вәкаләтле оешма) тапшырылган гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) гражданин (законлы вәкил) яисә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар мөрәҗәгать иткән көнне тикшерә.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә саналган документлар категориясенә карый торган документлар (документларның күчермәләре) тапшырылмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече гражданин (законлы вәкил), башка гражданин, дәүләт органы, җирле үзидарә органы, иҗтимагый оешма (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар мөрәҗәгать иткән очракта) социаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән көнне гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән һәм теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында, гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән һәм теркәүдән баш тартуның ачыкланган нигезләре эчтәлеген аңлатып, хәбәр итә һәм гаризаны һәм (яки) документларны (документларның күчермәләрен) кайтарып бирә.

Гаризаны Республика порталы, Бердәм портал аша тапшырган очракта, гаризаны һәм документларны теркәүдән баш тарту турында белдерү, баш тарту сәбәпләрен аңлатып, Республика порталына, Бердәм порталга мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

Гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы белгече (вәкаләтле оешма):

гаризаны гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен социаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында (алга таба – гаризаларны теркәү журналы) терки. Гаризаларны теркәү журналының формасы әлеге Регламентның 25 нче кушымтасында күрсәтелгән;

мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), башка гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин ихтыяҗларында башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) гаризаны теркәү датасы турында тамгалап, гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында язу тапшыра;

Министрлык тарафыннан расланган тәртиптә халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә гражданинның ятлар каравына индивидуаль мохтаҗлыгына, аның яшәешендәге чикләүләрнең структурасына һәм дәрәҗәсенә, сәламәтлегенең торышына, үз-үзен тотышындагы үзенчәлекләренә, тернәкләнү потенциалына һәм булган башка төрле ресурсларына карап (алга таба – типлаштыру) билгеләнгән гражданинның тормыш шартлары һәм ятлар каравына мохтаҗ булу дәрәҗәсе турында рәсми мөрәҗәгать җибәрә (рәсми мөрәҗәгать картлар һәм инвалидлар өчен интернет йортларында, психик тайпылышлардан интегә торган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларында өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтү, стационар формада социаль хезмәт күрсәтү, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләрендә көндезге бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлекчәләрендә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтү өчен гариза белдергән өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар буенча җибәрелә);

гаризаны һәм тапшырылган документларны Учреждениегә тапшыра (гариза һәм документлар Министрлыкның территориаль органына алынган очракта).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүчедән (законлы вәкилдән), башка гражданнардан, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) гариза һәм документлар алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза Республика порталы, Бердәм портал аша кергән очракта – гариза һәм документлар Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) алынган көнне яки, гариза белән документлар Министрлыкның территориаль органының (вәкаләтле оешманың) эш вакыты тәмамланганнан соң алынган очракта, киләсе эш көнендә. Гариза һәм документлар электрон документлар

рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Министрлыкның территориал органының (вәкаләтле оешманың) ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

баш тарту нигезләрен күрсәтеп, гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) теркәүгә алмыйча кире кайтару;

гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта – гаризаны теркәү датасы, алганда беркетелгән номеры турында тамгалап бирелгән язу;

Учреждениегә тапшырылган гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) (гариза һәм документлар Министрлыкның территориаль органына алынган очракта).

3.3. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү.

3.3.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза һәм документлар Учреждениегә (вәкаләтле оешмага) алынган көннән башлап бер эш көне эчендә Учреждениенең (вәкаләтле оешма) белгече тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле, гражданин (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) тарафыннан тапшырылмаган, әлеге Регламентның 13-23 кушымталарында күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр соратыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр тора.

3.3.2. Ведомствоара бәйләнештә катнаша торган орган яки оешма Учреждениегә (вәкаләтле оешмага) сорала торган белешмәләрне бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар сорала торган белешмәләр белән эш итүче дәүләт органына, җирле үзидарә органына, дәүләт органы яисә җирле үзидарә органына караган оешмага сорала торган белешмәләр буенча гариза алынган көннән башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып бирелгән белешмәләр тора.

3.4. Мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) үз инициативасы белән тапшырылган һәм (яисә) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган (бирелгән) документларны (документларның күчермәләрен) Учреждение белгече тарафыннан карау

Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

гаризаны, мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылган, шулай ук ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган (бирелгән) документларны (документларның күчермәләрен) карый һәм аларда күрсәтелгән белешмәләрне «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүне оештыру» ярдәмче системасына (алга таба – мәгълүмат системасы) кертә;

документларны (документларның күчермәләрен) өйрәнә һәм дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның тормыш шартларын начарайта яисә начарайта ала торган шартларны раслау, социаль хезмәтләр күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗ булуын билгеләү, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә медицина күрсәтүләре булуын (булмавын) билгеләү, тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген, документларның һәм белешмәләрнең гамәлдә булу вакытын ачыклау өчен кирәкле мәгълүматларны анализлый.

Документларны (белешмәләрне) карау һәм өйрәнү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигез булуы ачыкланган очракта, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар проектын әзерли (карар проекты 26 нчы кушымтада китерелгән);

мәгълүмат системасында әзерләнгән, гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар проектын кәгазьдә бастырып чыгара;

мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) кабул ителгән карар турында белдерү проектын әзерли;

Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешма директорына) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар проектын һәм мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), башка гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) белдерү проектын җибәрә.

Документларны (белешмәләрне) карау һәм өйрәнү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында

каралган нигезләрнең булмавы ачыкланса, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар проектын әзерли (карар проекты 26 нчы кушымтада китерелгән);

мәгълүмат системасында әзерләнгән, гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар проектын кәгазьдә бастырып чыгара;

гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар проектын, имзалау өчен, Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар – алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә, ә кичекмәстән социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны карау очрагында, кичекмәстән гамәлгә ашырыла.

Министрлыкның территориаль органына (учреждение директорына) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар проектын һәм мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), башка гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) белдерү проектын җибәрү административ процедураларның нәтиҗәсе булып тора.

3.5. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар кабул итү яисә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул итү

3.5.1. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар кабул итә һәм тиешле карар проектын һәм мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), башка гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) белдерү проектын имзалый.

Министрлыкның территориаль органы белгече имзаланган карарны һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) адресына имзаланган белдерүне алар Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе тарафыннан имзаланган көнне Учреждениегә тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.4 пунктында каралган процедура тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, ә ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кабул ителгән очракта – кичекмәстән.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан имзаланган карар һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) кабул ителгән карар турында белдерү;

Министрлыкның территориаль органы белгече тарафыннан Учреждениегә җибәрелгән, имзаланган карар һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) адресына имзаланган белдерү.

3.5.2. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта):

мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында, индивидуаль программаны төзү датасы һәм урыны турында хәбәр итә. Мәгълүмат җиткерү Республика порталында электрон формада гамәлгә ашырыла – гариза һәм документларны электрон рәвештә Республика порталы, Бердәм портал аша тапшырган очракта; телефон аша яки электрон почта аша яки язмача формада почта адресы буенча – гариза һәм документлар кәгазьдә бирелгән очракта;

яисә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында хәбәр җибәрә. Хәбәр Республика порталында электрон формада җибәрелә – гариза һәм документларны электрон рәвештә Республика порталы, Бердәм портал аша тапшырган очракта; язмача формада почта адресы буенча – гариза һәм документлар кәгазьдә бирелгән очракта.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан карар һәм белдерү проекты имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында, индивидуаль программа төзү датасы һәм урыны турында яисә мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында җибәрелгән белдерү тора.

3.6. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турындагы карар нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә гражданинның индивидуаль ихтыяҗларын билгеләү, гражданга индивидуаль программа төзү һәм бирү

3.6.1. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрә-

җәгать иткән очракта) тарафыннан тапшырылган документлар (документларның күчермәләре) һәм (яисә) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган, шул исәптән гаилә составын характерлый торган, гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар белән туганлык мөнәсәбәтләрен һәм гражданинның яшәеш шартларын характерлый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә социаль хезмәт күрсәтелә торган затның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын билгели.

Социаль хезмәтләр күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗны билгеләү нәтиҗәләре буенча мәгълүмат системасында Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече ике нөсхәдә индивидуаль программа проектын әзерли, аның формасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы килешүнең үрнәк формасы турында, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программа формасы турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 874н номерлы боерыгы белән расланган. Гражданин (законлы вәкил) индивидуаль программаны төзүдә катнашырга хокуклы.

Социаль куркыныч хәлдә булган, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган балигъ булмаган балага индивидуаль программа муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумы тарафыннан эшләнелә һәм раслана торган балигъ булмаганнарны тернәкләндерүнең индивидуаль программасын исәпкә алып төзелә.

Индивидуаль программа проекты төзегәннән соң Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече аның ике кәгазь нөсхәсен карап тикшерү һәм имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.5.2 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып, карап тикшерү һәм имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрелгән ике нөсхәдә индивидуаль программа проекты тора.

3.6.2. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) индивидуаль программаны карый һәм имзалый һәм аны мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) тапшыруны оештыру өчен Учреждение (вәкаләтле оешма) белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.6.1 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып, Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан ике нөсхәдә имзаланган һәм Учреждение белгеченә (вәкаләтле оешма) җибәрелгән индивидуаль программа проекты тора.

3.6.3. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) имзалаган ике нөсхәдә индивидуаль программасын алганнан соң, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә), датасын күрсәтеп, индивидуаль программаны алу өчен чакыру турында мәгълүмат бирә:

Республика порталында электрон формада – гариза һәм документлар электрон формада Республика порталы, Бердәм портал аша бирелгән очракта;

телефон аша яисә язма рәвештә почта адресы буенча – гариза һәм документлар кәгазьдә бирелгән очракта.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.6.2 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (мөрәҗәгать итүчегә), срогын (Учреждениедән хәбәр җибәрелгән көннән башлап 5 эш көне эчендә) күрсәтеп, Учреждениегә индивидуаль программаны алу өчен чакыру турында хәбәр итү тора.

3.6.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) индивидуаль программаны алу өчен Учреждениегә килгәч, Учреждение белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затны (законлы вәкилне) индивидуаль программаның эчтәлеге белән таныштыра;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) индивидуаль программаның ике нөсхәсен дә имзалагач, бер нөсхәне дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) бирә, индивидуаль программаның икенче нөсхәсен Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) җибәрә, белгеч дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның шәхси эшенә теркәп куя.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып имзаланган, ике нөсхәдәге индивидуаль программа, аның берсе дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) тапшырылган, икенчесе Министрлыкның территориаль органына җибәрелгән (вәкаләтле оешма белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның шәхси эшенә теркәп куелган).

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) әлеге Регламентның 3.6.3 пунктында күрсәтелгән срокта индивидуаль программаны алу өчен килмәгән очракта, индивидуаль программа юкка чыгарыла.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Индивидуаль программада техник хата ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) программаны биргән Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) түбәндәгеләрне тапшыра:

27 нче кушымта нигезендә техник хатаны төзәтү турында гариза;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) бирелгән, техник хатасы булган индивидуаль программа;

техник хатаның булуын таныклаучы документлар (документларның күчермәләре).

Индивидуаль программада күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә Бердәм портал аша, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша бирелә.

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра;

техник хаталарны төзәтү турында гаризаны Министрлыкның территориаль органына җибәрә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедура күпфункцияле үзәкнең эш регламентында һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

3.7.2. Министрлыкның территориаль органының (вәкаләтле оешманың) документларны кабул итү өчен җаваплы белгече гариза һәм документларны (документларның күчермәләрен) карый.

Индивидуаль программада техник хата булмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече индивидуаль программада техник хатаның булмавы турында дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) хәбәр итә һәм, гариза һәм (яки) документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, гаризаны һәм (яки) документларны аңа кайтарып бирә яки гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча яисә электрон адреска җибәрә.

Индивидуаль программада техник хата булган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны техник хатаны төзәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында терки (28 нче кушымта);

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында гаризаны теркәү датасы һәм индивидуаль программаны бирү датасы һәм урыны турында тамгалап, язу бирә.

Индивидуаль программа Министрлыкның территориаль органы тарафыннан расланган очракта, территориаль орган белгече гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) Учреждениегә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар техник хатаны төзәтү турында гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) теркәмичә кире кайтару яисә техник хатаны төзәтү турында гаризаларны теркәү журналында гаризаны теркәү турында язу; гаризаны теркәү датасы турында һәм

индивидуаль программаны бирү датасы һәм урыны турында күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында бирелгән язу; Министрлыкның территориаль органы тарафыннан Учреждениегә тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре).

3.7.3. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мәгълүмат системасында индивидуаль программага төзәтмәләр кертә;

ике нөсхәдә индивидуаль программаны кәгазьдә бастырып чыгара;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат адресына техник хатаны төзәтү турында белдерү проектын (алга таба – белдерү) әзерли;

индивидуаль программаның ике нөсхәсен һәм белдерү проектын имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар техник хатаны төзәтү турында гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) имзалау өчен җибәрелгән ике нөсхәдә индивидуаль программа проекты һәм белдерү проекты тора.

3.7.4. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) ике нөсхәдә индивидуаль программаны, белдерүне имзалый, аны Учреждение белгеченә (вәкаләтле оешма белгеченә) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.7.3 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып Министрлыкның территориаль органы тарафыннан Учреждениегә (вәкаләтле оешма директоры тарафыннан – вәкаләтле оешма белгеченә) җибәрелгән ике нөсхәдә имзаланган индивидуаль программа һәм белдерү тора.

3.7.5. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече әлеге Регламентның 3.6.3 пунктчасында каралган процедураларны башкара.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) язуда күрсәтелгән срокта килмәгән очракта, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече аңа белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.7.3 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) бирелгән индивидуаль программа, ә дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) язуда күрсәтелгән срокта килмәсә, аңа җибәрелгән белдерү тора.»;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә,

күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (хезмәткәрнең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (оешма) җитәкчесенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән, Идарәнең рәсми сайтыннан, Республика порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып, күпфункцияле үзәк аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында да кабул итеп алынырга мөмкин.»;

5.4 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлыкның территориаль органы (Учреждение, вәкаләтле оешма), дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи затының (учреждение, вәкаләтле оешма хезмәткәренең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

5.5 пунктында:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (оешманың), вазыйфаи затның (хезмәткәрнең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең исеме;»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (хезмәткәрнең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) вазыйфаи затының (хезмәткәренең) яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

5.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, бу Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган орган, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

әлеге Регламентка 4 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документлар исемлеге»;

әлеге Регламентка 5 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар өчен интернат йортларында, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документлар исемлеге»;

әлеге Регламентка 15 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернет йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны Татарстан Республикасының муниципаль районында (шәһәр округында) үзенең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органына мөстәкыйль тапшырырга хокуклы документлар исемлеге»;

әлеге Регламентка 16 нчы кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балаларның интернет йортларында, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернет йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны Татарстан Республикасының муниципаль районында (шәһәр округында) үзенең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органына мөстәкыйль тапшырырга хокуклыдокументлар исемлеге».

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2021 елның
20 сентябрендәге 670 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерыкта:

боерык атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

боерыкның 1 пунктында «социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта:

Административ регламент атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты»;

1 бүлектә:

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Учреждениенең урнашу урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, Министрлыкның рәсми сайты адресы, Министрлыкның электрон почтасы, Министрлыкның территориаль органнары, дәүләт хезмәте күрсәтергә вәкаләтле булган оешмаларының адреслары турындагы мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru) (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты, «Интернет» челтәре), «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы) урнаштырылган. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

1.4.2 пунктында:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында. Министрлыкның рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчасындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

Республика порталында;

Бердәм порталда.

Бердәм порталда, Республика порталында «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) күпфункцияле үзәккә һәм (яки) күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарына мөрәҗәгать иткәндә.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Әлеге Регламент максатларында түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү) – гражданнарга социаль хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеге;

социаль хезмәт күрсәтү – тормыш шартларын яхшырту һәм тормышындагы төп ихтыяҗларын мөстәкыйль тәэмин итә алу мөмкинлекләрен арттыру максатларында, гражданинга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә даими, билгеле бер вакыт ешлыгы белән, бер тапкыр, шул исәптән ашыгыч, ярдәм күрсәтү;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе бозылуга шикаять (алга таба – шикаять) – мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, дәүләт хезмәткәре яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмалар һәм аларның хезмәткәрләре тарафыннан мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алганда бозылган хокукларын яки законлы мәнфәгатьләрен торгызу яки яклау турында таләп итүе;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада да, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләт бирелгән оешма;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

ИАБС – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 3 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать. Гаризаның формасы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза формасын раслау турында» 2014 елның 28 мартындагы 159н номерлы боерыгы (алга таба – РФ Хезмәт министрлыгының 159н номерлы боерыгы) белән расланган.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү.

2.2. Башкарма хакимият органының исеме

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында (шәһәр округларында) гражданинның яшәү урыны (тору урыны) буенча Социаль яклау идарәләре (бүлекләре) аша Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

Министрлык тарафыннан гражданнарны балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм Татарстан Республикасының бер яисә берничә муниципаль берәмлеге территориясендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү вәкаләте бирелгән балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләре (әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы исемлек).

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын (алга таба – индивидуаль программа) төзү;

яисә гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту.

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану очрагында аңа (аның законлы вәкиленә) социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү датасы һәм урыны турында хәбәр ителә.

2.3.2. Кабул ителгән карар турында мәгълүмат рәвешендә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә аны алу буенча сайлаган ысул белән җибәрелә:

почта аша язма рәвештә;

электрон документ формасында электрон почта адресы яки мөрәҗәгать итүченең Республика порталындагы шәхси кабинетына.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану яисә гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар гариза тапшырылган көннән башлап биш эш көне эчендә кабул ителә.

Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кичекмәстән кабул ителә.

2.4.2. Гариза тапшырылганнан соң ун эш көненнән артмаган вакыт эчендә гражданинга социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы төзелә һәм аның төзелүе һәм аны алу өчен территориаль органга чакыру турында хәбәр җибәрелә.

Ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы төзелми.

2.4.3. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

## 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза бирә:

РФ Хезмәт министрлыгының №159н боерыгы белән расланган форма буенча кәгазьдә;

Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, әлеге пункт таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле белешмәләрне кертү юлы белән тутырыла).

2.5.2. Комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка 2 нче кушымтадагы исемлеккә туры китереп документлар да тапшыра.

Картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларында (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 3 кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернет йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 4 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балаларның интернет йортларында, физик җитешсезлекләре булган балаларның интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 5 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә стационар формада социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ булган балигълык яшенә җитмәгән затлар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигълык яшенә җитмәгәннәр өчен социаль

тернәкләндерү үзәкләре) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка 7 нче кушымтадагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән бергә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 8 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Яшәү белән бергә алып барыла торган уку (күнекмә алу) курсы кысаларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентка 8[1] кушымтадагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм итү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 9 нчы кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән бергә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 10 нчы кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Сукырларны һәм начар күрә торган затларны социаль тернәкләндерү үзәгендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 11 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

2020-2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру буенча сынау проектында катнаша торган социаль хезмәт күрсәтүче затлар тарафыннан көндезге бүлекчәләрдә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән бергә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 11[1] кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм итү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза белән берлектә мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 12 нче кушымтасындагы исемлек буенча документлар тапшыра.

Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза биргәндә мөрәҗәгать итүче шәхесне раслый торган документ күрсәтә. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза законлы вәкил тарафыннан тапшырылган очракта яисә мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләрнең вәкилләре мөрәҗәгать

иткән очракта, вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен таныклый торган документлар күрсәтелә.

Документларның күчермәләре, Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта, оригиналларын күрсәтеп, Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи заты тарафыннан расланa.

2.5.3. Гариза һәм теркәп тапшырыла торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән;

почта аша почта юлламасы белән;

Республика порталы аша электрон формада;

күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы (алга таба – Бердәм портал) аша электрон формада.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар. Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

Гаризаны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша яисә Республика порталы, Бердәм портал аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага), күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урынына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин.

Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы,

җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәге документлар алына:

әлеге Регламентның 13 нче кушымтасындагы исемлек буенча халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында;

әлеге Регламентның 14 нче кушымтасындагы исемлек буенча картлар һәм инвалидлар өчен интернат йортларында (пансионатларда), картлар һәм инвалидлар өчен махсус интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентка 15 нче кушымтадагы исемлек буенча психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентка 16 нчы кушымтадагы исемлек буенча психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балаларның интернет йортларында, физик җитешсезлекләре булган балаларның интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентка 17 нче кушымтадагы исемлек буенча инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентның 18 нче кушымтасындагы исемлек буенча социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ булган балигъ булмаган яшенә җитмәгән затлар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә (балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютлар, балигъ булмаган яшенә җитмәгәннәр өчен социаль тернәкләндерү үзәкләре) социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентка 19 нчы кушымтадагы исемлек буенча билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

$19^1$ кушымтадагы исемлек буенча яшәү белән бергә алып барыла торган уку (күнекмә алу) курсы кысаларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында;

әлеге Регламентның 20 нче кушымтасындагы исемлек буенча гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм итү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында;

әлеге Регламентка 21 нче кушымтадагы исемлек буенча халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең социаль-тернәкләндерү бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләрендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында;

әлеге Регламентка 22 нче кушымтадагы исемлек буенча сукырлар һәм

начар күрүчеләрне социаль тернәкләндерү үзәгендә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында;

әлеге Регламентның 22[1] кушымтасындагы исемлек буенча 2020-2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын оештыру бөенча сынау проектында катнаша торган социаль хезмәт күрсәтүче затлар тарафыннан көндезге бүлекчәләрдә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында;

әлеге Регламентның 23 нче кушымтасындагы исемлек буенча гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм итү үзәкләрендә, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында;

Мөрәҗәгать итүче Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча мөрәҗәгать итүченең паспорты чын булуын раслау турындагы мәгълүмат та алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).

2.6.2. Әлеге пунктта күрсәтелгән документларны, гади электрон имза белән имзаланган электрон формада, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, аша Министрлыкның территориаль органына мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән;

почта аша почта юлламасы белән.

2.6.3. Югарыда күрсәтелгән документлар әлеге Регламентның 13-23 кушымталарында күрсәтелгән оешмалардан һәм учреждениеләрдән, тиешле федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларында (норматив актларында) билгеләнгән ысуллар белән алынырга мөмкин.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән документларның тапшырылмавы дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларны кабул итүдән баш тартуга нигез була алмый.

Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

Әлеге органнарның соралган һәм карамакта булган документны яки мәгълүматны тапшырмаган (үз вакытында тапшырмаган) вазыйфаи заты һәм (яки) хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә административ, дисциплинар яки башка төрле җаваплылыкка тартылырга тиешле була.

2.6.5. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы

яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

2) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;

3) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны.

4) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә элегрәк электрон үрнәкләре таныкланган документларны һәм мәгълүматларны кәгазьдә тапшыруны, мондый документларга тамгалар кертү яки аларны бетерү дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан тыш һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

### 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту (документларны асылы буенча карамыйча кире кайтару) нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:

1) әлеге Регламентның 2.5.2 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырылырга тиешле документларның тапшырылмавы;

2) документларның тиешле булмаган органга тапшырылуы;

3) төгәл булмаган һәм (яки) кара-каршы килә торган белешмәләр, җитди, эчтәлеген бер мәгънәдә аңлау мөмкинлеген бирми торган җитешсезлекләре булган документларның, гамәлдән чыккан документларның тапшырылуы, тапшырылган документларда чистартылган, өстәп язылган, сызып ташланган сүзләр һәм билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган төзәтүләр булуы;

4) күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү;

5) мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе;

6) гаризаның электрон формасындагы мәҗбүри кырларны төгәл тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булуы;

7) 63-ФЗ номерлы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законнар таләпләре

нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон формадагы гариза (мөрәҗәгать) һәм башка документлар;

8) электрон документларның аларның форматларына карата таләпләргә туры килмәве һәм (яки) укылмавы;

9) законлы вәкилләр турында мөрәҗәгать итүче тапшырган белешмәләрнең расланмавы, гризаның (рәсми мөрәҗәгатьнең) мөрәҗәгать итүче исеменнән моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең исемлеге тулы булып тора.

2.7.3. Гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибендә Бердәм порталда, Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында басылып чыккан мәгълүматка туры китереп тапшырылган булса, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезләре каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру, гамәлдә булу срогы чыккан документлар һәм белешмәләр бирү;

2) гражданинның тормыш эшчәнлеге шартларын начарайта яисә начарайта ала торган шартлар булмавы;

3) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган, социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен медицина каршылыкларының булуы ачыклану.

4) законлы вәкилләр турында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алынган белешмәләрнең расланмавы, гаризаның (рәсми мөрәҗәгатьнең) мөрәҗәгать итүче исеменнән моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшырылуы.

2.8.2. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Республика порталында, Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

## 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры

2.12.1. Мөрәҗәгать итүчене кабул итү (хезмәт күрсәтү) көтү вакытының максималь вакыты 15 минуттан артмый.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затларның аерым категорияләре өчен кабул итүне көтү чираты билгеләнмәгән.

## 2.13. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын һәм документларны, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү чоры һәм тәртибе

2.13.1. Шәхсән мөрәҗәгат иткән очракта, гариза һәм документлар алынган көнне.

2.13.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада алынган гаризалар һәм документлар ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

## 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктының 1 пунктчасында

каралган мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга тоткарлыксыз үтеп керә алу максатларында, түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән хезмәттән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, хезмәтләр күрсәтелә торган объектка озата йөри торган этне кертү.

2.14.3. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, хезмәт күрсәтү;

в) хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүче органнар һәм оешмалар хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, аларга хезмәт күрсәтүгә комачаулый торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) хезмәт күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-ноктагы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.14.4. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.15. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән һәркемнең файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән дә файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгать) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен (шул исәптән тулы күләмдә) күрсәтү мөмкинлегенең булуы яки булмавы

2.15.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачау итүче каршылыкларны җиңәргә ярдәм күрсәтелүе;

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге.

2.15.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Министрлыкның территориаль органы (учреждение, вәкаләтле оешма) белгечлщре тарафыннан Регламент бозылуга карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Министрлыкның территориаль органы (учреждение, вәкаләтле оешма) белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен кирәкле документлар турыдан-туры тапшырылганда – икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

гариза һәм документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль законның һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләре нигезендә гади электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар формасында җибәрелгән очракта, – бер тапкырдан артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.15.3. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы белгечләр белән бер тапкыр үзара хезмәттәшлек итүенең вакыты буенча озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.15.4. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.

2.15.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турындагы мәгълүматны түбәндәгечә алырга мөмкин:

гаризаны һәм документларны Республика порталы, Бердәм портал аша биргән мөрәҗәгать итүче тарафыннан – Республика порталында, Бердәм порталда;

гаризаны һәм документларны кәгазь чыганакта тапшырган мөрәҗәгать итүче тарафыннан – гариза буенча почта адресына кәгазь чыганакта.

күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынында.

2.15.5. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына мөрәҗәгать иткәндә, гариза Министрлыкның территориаль органына теркәлгән көннән соң икенче эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлыкның территориаль органы белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – Министрлык һәм күпфункцияле үзәк арасында төзелә торган хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

2.15.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

### 2.16. Экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр

2.16.1. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге 7.2 пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм документларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Республика порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон формада алырга;

е) Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Министрлыкның территориаль органы, Учреждение, Вәкаләтле оешма белгече, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Мөрәҗәгать итүчеләрне Министрлыкның территориаль органына кабул итү өчен язу (алга таба – кабул итүгә язылу) Республика порталы, Бердәм портал аша гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүчегә Министрлыкның территориаль органында билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә буш булган теләсә нинди кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Республика порталы, Бердәм портал аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номеры;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланып, 15 минут узганнан соң да килмәгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә алдан язылуның

гамәлдән чыгарылуы турында зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.16.4. Гариза Республика порталы, Бердәм портал аша җибәрелергә мөмкин.

Гариза Республика порталы, Бердәм портал аша бирелгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе электрон формада бирелә.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә гамәлгә ашыру үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама:

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүче тапшырган гаризаны һәм документлар комплектын кабул итү һәм карау;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

4) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

3.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны һәм тапшырылган документларны (документларның күчермәләрен) карау, социаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны (мөрәҗәгатьне) социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булу турында карар кабул итү өчен кирәкле документларны (документларның күчермәләре) белән бергә кабул итү һәм теркәү яисә гариза белән документларны кабул итүдән баш тарту.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыра.

Социаль хезмәт күрсәтүгә ихтыяҗ булуын билгели торган, гаризада (мөрәҗәгатьтә) күрсәтелгән шартлар булуын раслый торган документлар (документларның күчермәләре) гариза белән берлектә гражданин (аның законлы вәкиле) тарафыннан, ә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре мөрәҗәгать иткән очракта – башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмаларның вәкилләре тарафыннан тапшырыла, ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү очраклары искәрмә булып тора.

Гариза һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган документларның күчермәләре почта юлламасы итеп җибәрелергә мөмкин.

3.2.2. Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Республика порталында, Бердәм порталда авторизацияләнә;

Республика порталында, Бердәм порталда гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга билгели);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.5.4 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның һәм документларның җибәрелүе турында белдерү ала.

Почта аша тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре), электрон формада Республика порталы, Бердәм портал, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) гомуми тәртиптә карала.

3.2.3. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк белгече мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документациянең составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән алырга мөмкин.

3.2.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә законлы вәкиле аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар теркәп, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урынына кәгазьдә гариза һәм документлар тапшыра ала.

Күпфункцияле үзәкнең гаризаларны һәм документларны кабул итә торган белгече күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар.

3.2.4. Күпфункцияле үзәк белгече гариза һәм документларны Министрлыкның территориаль органына җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлыкның территориаль органы белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек итү тәртибе – хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе күпфункцияле үзәкнең эш регламентында җайга салына.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның территориаль органына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларның алынуы административ процедура үтәлешен башлау нигезе булып тора.

Министрлыкның территориаль органы белгече (вәкаләтле оешма) тапшырылган гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) гражданин (законлы вәкил) яисә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар мөрәҗәгать иткән көнне тикшерә.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә саналган документлар категориясенә карый торган документлар (документларның күчермәләре) тапшырылмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече гражданин (законлы вәкил), башка гражданин, дәүләт органы, җирле үзидарә органы, иҗтимагый оешма (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар мөрәҗәгать иткән очракта) социаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән көнне гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән һәм теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында, гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән һәм теркәүдән баш тартуның ачыкланган нигезләре эчтәлеген аңлатып, хәбәр итә һәм гаризаны һәм (яки) документларны (документларның күчермәләрен) кайтарып бирә.

Гаризаны Республика порталы, Бердәм портал аша тапшырган очракта, гаризаны һәм документларны теркәүдән баш тарту турында белдерү, баш тарту сәбәпләрен аңлатып, Республика порталына, Бердәм порталга мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрелә.

Гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы белгече (вәкаләтле оешма):

гаризаны гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен социаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында (алга таба – гаризаларны теркәү журналы) терки. Гаризаларны теркәү журналының формасы әлеге Регламентның 25 нче кушымтасында күрсәтелгән;

мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), башка гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин ихтыяҗларында башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) гаризаны теркәү датасы турында тамгалап, гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында язу тапшыра;

Министрлык тарафыннан расланган тәртиптә халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә гражданинның ятлар каравына индивидуаль мохтаҗлыгына, аның яшәешендәге чикләүләрнең структурасына һәм дәрәҗәсенә, сәламәтлегенең торышына, үз-үзен тотышындагы үзенчәлекләренә, тернәкләнү потенциалына һәм булган башка төрле ресурсларына карап (алга таба – типлаштыру) билгеләнгән гражданинның тормыш шартлары һәм ятлар каравына мохтаҗ булу дәрәҗәсе турында рәсми мөрәҗәгать җибәрә (рәсми мөрәҗәгать картлар һәм инвалидлар өчен интернет йортларында, психик тайпылышлардан интегә торган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларында өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтү, стационар формада социаль хезмәт күрсәтү, халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләрендә көндезге бүлекчәләрендә, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлекчәләрендә социаль хезмәт күрсәтү формасында социаль хезмәт күрсәтү өчен гариза белдергән өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар буенча җибәрелә);

гаризаны һәм тапшырылган документларны Учреждениегә тапшыра (гариза һәм документлар Министрлыкның территориаль органына алынган очракта).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүчедән (законлы вәкилдән), башка гражданнардан, дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) гариза һәм документлар алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар алынган көнне;

гариза Республика порталы, Бердәм портал аша кергән очракта – гариза һәм документлар Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) алынган көнне яки, гариза белән документлар Министрлыкның территориаль органының (вәкаләтле оешманың) эш вакыты тәмамланганнан соң алынган очракта, киләсе эш көнендә. Гариза һәм документлар электрон документлар

рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Министрлыкның территориал органының (вәкаләтле оешманың) ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

баш тарту нигезләрен күрсәтеп, гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) теркәүгә алмыйча кире кайтару;

гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы, шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта – гаризаны теркәү датасы, алганда беркетелгән номеры турында тамгалап бирелгән язу;

Учреждениегә тапшырылган гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) (гариза һәм документлар Министрлыкның территориаль органына алынган очракта).

3.3. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү.

3.3.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гариза һәм документлар Учреждениегә (вәкаләтле оешмага) алынган көннән башлап бер эш көне эчендә Учреждениенең (вәкаләтле оешма) белгече тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле, гражданин (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) тарафыннан тапшырылмаган, әлеге Регламентның 13-23 кушымталарында күрсәтелгән документлар һәм белешмәләр соратыла.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көндә башкарыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мәгълүмат бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр тора.

3.3.2. Ведомствоара бәйләнештә катнаша торган орган яки оешма Учреждениегә (вәкаләтле оешмага) сорала торган белешмәләрне бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар сорала торган белешмәләр белән эш итүче дәүләт органына, җирле үзидарә органына, дәүләт органы яисә җирле үзидарә органына караган оешмага сорала торган белешмәләр буенча гариза алынган көннән башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып бирелгән белешмәләр тора.

3.4. Мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) үз инициативасы белән тапшырылган һәм (яисә) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган (бирелгән) документларны (документларның күчермәләрен) Учреждение белгече тарафыннан карау

Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

гаризаны, мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылган, шулай ук ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган (бирелгән) документларны (документларның күчермәләрен) карый һәм аларда күрсәтелгән белешмәләрне «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасының «Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүне оештыру» ярдәмче системасына (алга таба – мәгълүмат системасы) кертә;

документларны (документларның күчермәләрен) өйрәнә һәм дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның тормыш шартларын начарайта яисә начарайта ала торган шартларны раслау, социаль хезмәтләр күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗ булуын билгеләү, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә медицина күрсәтүләре булуын (булмавын) билгеләү, тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген, документларның һәм белешмәләрнең гамәлдә булу вакытын ачыклау өчен кирәкле мәгълүматларны анализлый.

Документларны (белешмәләрне) карау һәм өйрәнү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигез булуы ачыкланган очракта, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар проектын әзерли (карар проекты 26 нчы кушымтада китерелгән);

мәгълүмат системасында әзерләнгән, гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар проектын кәгазьдә бастырып чыгара;

мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) кабул ителгән карар турында белдерү проектын әзерли;

Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешма директорына) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар проектын һәм мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), башка гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) белдерү проектын җибәрә.

Документларны (белешмәләрне) карау һәм өйрәнү нәтиҗәләре буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында

каралган нигезләрнең булмавы ачыкланса, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мәгълүмат системасында гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар проектын әзерли (карар проекты 26 нчы кушымтада китерелгән);

мәгълүмат системасында әзерләнгән, гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар проектын кәгазьдә бастырып чыгара;

гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар проектын, имзалау өчен, Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар – алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә, ә кичекмәстән социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны карау очрагында, кичекмәстән гамәлгә ашырыла.

Министрлыкның территориаль органына (учреждение директорына) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар проектын һәм мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), башка гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) белдерү проектын җибәрү административ процедураларның нәтиҗәсе булып тора.

3.5. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында карар кабул итү яисә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында карар кабул итү

3.5.1. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану (танудан баш тарту) турында карар кабул итә һәм тиешле карар проектын һәм мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), башка гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) белдерү проектын имзалый.

Министрлыкның территориаль органы белгече имзаланган карарны һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) адресына имзаланган белдерүне алар Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе тарафыннан имзаланган көнне Учреждениегә тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.4 пунктында каралган процедура тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, ә ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турында карар кабул ителгән очракта – кичекмәстән.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан имзаланган карар һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) кабул ителгән карар турында белдерү;

Министрлыкның территориаль органы белгече тарафыннан Учреждениегә җибәрелгән, имзаланган карар һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта) адресына имзаланган белдерү.

3.5.2. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр адресына (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракта):

мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында, индивидуаль программаны төзү датасы һәм урыны турында хәбәр итә. Мәгълүмат җиткерү Республика порталында электрон формада гамәлгә ашырыла – гариза һәм документларны электрон рәвештә Республика порталы, Бердәм портал аша тапшырган очракта; телефон аша яки электрон почта аша яки язмача формада почта адресы буенча – гариза һәм документлар кәгазьдә бирелгән очракта;

яисә социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында хәбәр җибәрә. Хәбәр Республика порталында электрон формада җибәрелә – гариза һәм документларны электрон рәвештә Республика порталы, Бердәм портал аша тапшырган очракта; язмача формада почта адресы буенча – гариза һәм документлар кәгазьдә бирелгән очракта.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан карар һәм белдерү проекты имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында, индивидуаль программа төзү датасы һәм урыны турында яисә мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танудан баш тарту турында җибәрелгән белдерү тора.

3.6. Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турындагы карар нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә гражданинның индивидуаль ихтыяҗларын билгеләү, гражданга индивидуаль программа төзү һәм бирү

3.6.1. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрә-

җәгать иткән очракта) тарафыннан тапшырылган документлар (документларның күчермәләре) һәм (яисә) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган, шул исәптән гаилә составын характерлый торган, гражданинның яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар белән туганлык мөнәсәбәтләрен һәм гражданинның яшәеш шартларын характерлый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә социаль хезмәт күрсәтелә торган затның социаль хезмәт күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗын билгели.

Социаль хезмәтләр күрсәтүгә индивидуаль ихтыяҗны билгеләү нәтиҗәләре буенча мәгълүмат системасында Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече ике нөсхәдә индивидуаль программа проектын әзерли, аның формасы Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы килешүнең үрнәк формасы турында, шулай ук социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программа формасы турында» 2014 елның 10 ноябрендәге 874н номерлы боерыгы белән расланган. Гражданин (законлы вәкил) индивидуаль программаны төзүдә катнашырга хокуклы.

Социаль куркыныч хәлдә булган, социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган балигъ булмаган балага индивидуаль программа муниципаль социаль-тернәкләндерү консилиумы тарафыннан эшләнелә һәм раслана торган балигъ булмаганнарны тернәкләндерүнең индивидуаль программасын исәпкә алып төзелә.

Индивидуаль программа проекты төзегәннән соң Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече аның ике кәгазь нөсхәсен карап тикшерү һәм имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.5.2 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып, карап тикшерү һәм имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрелгән ике нөсхәдә индивидуаль программа проекты тора.

3.6.2. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) индивидуаль программаны карый һәм имзалый һәм аны мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә) тапшыруны оештыру өчен Учреждение (вәкаләтле оешма) белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.6.1 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып, Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) тарафыннан ике нөсхәдә имзаланган һәм Учреждение белгеченә (вәкаләтле оешма) җибәрелгән индивидуаль программа проекты тора.

3.6.3. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) имзалаган ике нөсхәдә индивидуаль программасын алганнан соң, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә), датасын күрсәтеп, индивидуаль программаны алу өчен чакыру турында мәгълүмат бирә:

Республика порталында электрон формада – гариза һәм документлар электрон формада Республика порталы, Бердәм портал аша бирелгән очракта;

телефон аша яисә язма рәвештә почта адресы буенча – гариза һәм документлар кәгазьдә бирелгән очракта.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.6.2 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (мөрәҗәгать итүчегә), срогын (Учреждениедән хәбәр җибәрелгән көннән башлап 5 эш көне эчендә) күрсәтеп, Учреждениегә индивидуаль программаны алу өчен чакыру турында хәбәр итү тора.

3.6.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) индивидуаль программаны алу өчен Учреждениегә килгәч, Учреждение белгече:

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затны (законлы вәкилне) индивидуаль программаның эчтәлеге белән таныштыра;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) индивидуаль программаның ике нөсхәсен дә имзалагач, бер нөсхәне дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) бирә, индивидуаль программаның икенче нөсхәсен Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) җибәрә, белгеч дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның шәхси эшенә теркәп куя.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып имзаланган, ике нөсхәдәге индивидуаль программа, аның берсе дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) тапшырылган, икенчесе Министрлыкның территориаль органына җибәрелгән (вәкаләтле оешма белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затның шәхси эшенә теркәп куелган).

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) әлеге Регламентның 3.6.3 пунктында күрсәтелгән срокта индивидуаль программаны алу өчен килмәгән очракта, индивидуаль программа юкка чыгарыла.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Индивидуаль программада техник хата ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) программаны биргән Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешмага) түбәндәгеләрне тапшыра:

27 нче кушымта нигезендә техник хатаны төзәтү турында гариза;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) бирелгән, техник хатасы булган индивидуаль программа;

техник хатаның булуын таныклаучы документлар (документларның күчермәләре).

Индивидуаль программада күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә Бердәм портал аша, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша бирелә.

Гаризаны күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша тапшырган очракта, күпфункцияле үзәкнең гаризаларны кабул итә торган белгече:

күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра;

техник хаталарны төзәтү турында гаризаны Министрлыкның территориаль органына җибәрә.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедура күпфункцияле үзәкнең эш регламентында һәм үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

3.7.2. Министрлыкның территориаль органының (вәкаләтле оешманың) документларны кабул итү өчен җаваплы белгече гариза һәм документларны (документларның күчермәләрен) карый.

Индивидуаль программада техник хата булмаган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече индивидуаль программада техник хатаның булмавы турында дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) хәбәр итә һәм, гариза һәм (яки) документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, гаризаны һәм (яки) документларны аңа кайтарып бирә яки гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча яисә электрон адреска җибәрә.

Индивидуаль программада техник хата булган очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны техник хатаны төзәтү турындагы гаризаларны теркәү журналында терки (28 нче кушымта);

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында гаризаны теркәү датасы һәм индивидуаль программаны бирү датасы һәм урыны турында тамгалап, язу бирә.

Индивидуаль программа Министрлыкның территориаль органы тарафыннан расланган очракта, территориаль орган белгече гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) Учреждениегә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар техник хатаны төзәтү турында гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) теркәмичә кире кайтару яисә техник хатаны төзәтү турында гаризаларны теркәү журналында гаризаны теркәү турында язу; гаризаны теркәү датасы турында һәм

индивидуаль программаны бирү датасы һәм урыны турында күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм документларны (документларның күчермәләрен) кабул итү турында бирелгән язу; Министрлыкның территориаль органы тарафыннан Учреждениегә тапшырылган гариза һәм документлар (документларның күчермәләре).

3.7.3. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече:

мәгълүмат системасында индивидуаль программага төзәтмәләр кертә;

ике нөсхәдә индивидуаль программаны кәгазьдә бастырып чыгара;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат адресына техник хатаны төзәтү турында белдерү проектын (алга таба – белдерү) әзерли;

индивидуаль программаның ике нөсхәсен һәм белдерү проектын имзалау өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар техник хатаны төзәтү турында гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма директорына) имзалау өчен җибәрелгән ике нөсхәдә индивидуаль программа проекты һәм белдерү проекты тора.

3.7.4. Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) ике нөсхәдә индивидуаль программаны, белдерүне имзалый, аны Учреждение белгеченә (вәкаләтле оешма белгеченә) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.7.3 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып Министрлыкның территориаль органы тарафыннан Учреждениегә (вәкаләтле оешма директоры тарафыннан – вәкаләтле оешма белгеченә) җибәрелгән ике нөсхәдә имзаланган индивидуаль программа һәм белдерү тора.

3.7.5. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече әлеге Регламентның 3.6.3 пунктчасында каралган процедураларны башкара.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) язуда күрсәтелгән срокта килмәгән очракта, Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече аңа белдерү җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.7.3 пунктчасында каралган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган затка (законлы вәкилгә) бирелгән индивидуаль программа, ә дәүләт хезмәте күрсәтелә торган зат (законлы вәкил) язуда күрсәтелгән срокта килмәсә, аңа җибәрелгән белдерү тора.»;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә,

күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (хезмәткәрнең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган (оешма) җитәкчесенең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән, Идарәнең рәсми сайтыннан, Республика порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып, күпфункцияле үзәк аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында да кабул итеп алынырга мөмкин.»;

5.4 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлыкның территориаль органы (Учреждение, вәкаләтле оешма), дәүләт хезмәте күрсәтә торган Министрлыкның территориаль органы вазыйфаи затының (учреждение, вәкаләтле оешма хезмәткәренең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

5.5 пунктында:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (оешманың), вазыйфаи затның (хезмәткәрнең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең исеме;»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (хезмәткәрнең), күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (оешманың), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (оешманың) вазыйфаи затының (хезмәткәренең) яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

5.6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.6.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, бу Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтелә торган орган, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

әлеге Регламентка 4 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документлар исемлеге»;

әлеге Регламентка 5 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар өчен интернат йортларында, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернат йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документлар исемлеге»;

әлеге Регламентка 15 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернет йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны Татарстан Республикасының муниципаль районында (шәһәр округында) үзенең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органына мөстәкыйль тапшырырга хокуклы документлар исемлеге»;

әлеге Регламентка 16 нчы кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән балаларның интернет йортларында, физик җитешсезлекләре булган балалар өчен интернет йортларында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар формасында социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны Татарстан Республикасының муниципаль районында (шәһәр округында) үзенең яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органына мөстәкыйль тапшырырга хокуклыдокументлар исемлеге».